**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче Какылы Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«26» ноябрь 2022 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 26 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Какылы Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән,көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- зиратта агач кисү (килешү буенча эш өчен түләү);
- санкцияләнмәгән чүплекне бетерү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү)" соравы буенча.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 83 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 45 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда 42 кеше тавыш бирде;
- «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы Күл торак пунктында халык җыенын узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Какылы Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән,көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- зиратта агач кисү (килешү буенча эш өчен түләү);
- санкцияләнмәгән чүплекне бетерү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү)" буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова